КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 27 июнь

г.Казань

№ 611

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарын һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр күрсәтә торган социаль хезмәтләрне финанслауның җан башына нормативларын хисаплап чыгару тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2009 ел, 31 декабрь, 915 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарын һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр күрсәтә торган социаль хезмәтләрне финанслауның җан башына нормативларын хисаплап чыгару тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарын һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр күрсәтә торган социаль хезмәтләрне финанслауның җан башына нормативларын хисаплап чыгару тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2009 ел, 31 декабрь, 915 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 30 декабрь, 1097 нче; 2014 ел, 31 декабрь, 1096 нчы; 2015 ел,

6 ноябрь, 325 нче; 2015 ел, 12 ноябрь, 847 нче; 2016 ел, 1 март, 127 нче; 2016 ел, 4 июнь, 372 нче; 2017 ел, 12 май, 276 нчы; 2017 ел, 29 июль, 529 нчы; 2017 ел, 28 август, 609 нчы; 2018 ел, 18 июнь, 493 нче; 2018 ел, 12 сентябрь, 773 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1218 нче; 2019 ел, 7 сентябрь, 800 нче, 2019 ел, 16 декабрь, 1154 нче; 2020 ел, 25 август, 731 нче; 2020 ел, 9 октябрь, 915 нче; 2020 ел, 25 декабрь, 1192 нче, 2021 ел, 6 сентябрь, 811 нче, 2021 ел, 25 сентябрь, 914 нче, 2022 ел, 22 гыйнвар, 38 нче, 2022 ел, 17 май, 452 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарын һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр күрсәтә торган социаль хезмәтләрне финанслауның җан башына нормативларын хисаплап чыгару тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

26 нче таблицада:

исемендә «балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютларда, социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендәге балигъ булмаганнар өчен социаль-тернәкләндерү үзәкләрендә,» сүзләрен төшереп калдырырга;

таблицаның башында «Балалар өчен социаль приютлар, балигъ булмаганнар өчен социаль-тернәкләндерү үзәкләре, мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен тернәкләндерү үзәкләре» сүзләрен «Мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен тернәкләндерү үзәкләре» сүзләренә алмаштырырга;

3.3 пунктның 3 графасында «литр» сүзен «грамм» сүзенә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле $26^1$ нче таблица өстәргә:

«$26^1$ нче таблица Балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютларда, социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендәге балигъ булмаганнар өчен социаль тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүләр алучыларны туклану белән тәэмин итү нормалары

| Т/с | Азык-төлек продуктлары исеме | Үлчәү берәмлеге | Яше | | | Көненә бер урынга уртача норма |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 3 яшь - 6 яшь | 7 - 11 яшь | 12 яшь һәм өлкәнрәк | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 1. | Арыш икмәге | граммнар | 50,0 | 100,0 | 150,0 | 100,0 |
| 2. | Бодай икмәге | граммнар | 90,0 | 200,0 | 250,0 | 180,0 |
| 3. | Бодай оны | граммнар | 25,0 | 40,0 | 42,0 | 35,7 |
| 4. | Крахмал | граммнар | 2,0 | 3,0 | 3,0 | 2,7 |
| 5. | Ярма, кузаклылар, макарон эшләнмәләре | граммнар | 45,0 | 60,0 | 75,0 | 60,0 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 6. | Бәрәңге | грамм-нар | 240,0 | 300,0 | 400,0 | 313,3 |
| 7. | Яшелчәләр (яңа, тундырылган), тозлы һәм әчетелгән (гомуми яшелчәләрнең 10 процентыннан артык түгел), шул исәптән томат-пюре, яшел тәмләткечләрне дә кертеп | грамм-нар | 300,0 | 400,0 | 475,0 | 391,7 |
| 8. | Җиләк-җимеш | грамм-нар | 260,0 | 300,0 | 300,0 | 286,7 |
| 9. | Җиләк-җимеш соклары | грамм-нар | 200,0 | 200,0 | 200,0 | 200,0 |
| 10. | Кипкән җиләк-җимеш | грамм-нар | 15,0 | 15,0 | 20,0 | 16,7 |
| 11. | Шикәр (шул исәптән, шикәр булган сәнәгать чыгарылышының азык-төлек продукциясе кулланылган очракта, азык-төлек һәм эчемлекләр әзерләү өчен, аның кулланылучы әзер азык-төлек продукциясендәге эчтәлегенә карап шикәр киметелергә тиеш) | грамм-нар | 55,0 | 65,0 | 70,0 | 63,3 |
| 12. | Кондитер эшләнмәләре | грамм-нар | 25,0 | 30,0 | 30,0 | 28,3 |
| 5 % | Кофе (кофе эчемлеге) | грамм-нар | 2,0 | 2,0 | 2,0 | 2,0 |
| 14. | Какао | грамм-нар | 0,5 | 2,0 | 2,0 | 1,5 |
| 15. | Чәй | грамм-нар | 0,5 | 1,0 | 1,0 | 0,8 |
| 16. | Беренче категорияле ит (шул исәптән субпродуктлар - бавыр, тел, йөрәк) | грамм-нар | 100,0 | 110,0 | 110,0 | 106,7 |
| 17. | Беренче категорияле кошкорт (чистартылган тавыклар, бройлер чебиләр, чистартылган күркә) | грамм-нар | 30,0 | 40,0 | 50,0 | 40,0 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 18. | Балык-филе, шул исәптән филе аз тозлы филе | грамм-нар | 42,0 | 80,0 | 110,0 | 77,3 |
| 19. | Колбаса эшләнмәләре | грамм-нар | 10,0 | 25,0 | 25,0 | 20,0 |
| 20. | Сөт, әче сөт продуктлары | грамм-нар | 550,0 | 500,0 | 500,0 | 516,7 |
| 21. | Эремчек (майның масса өлеше 5 - 9 процент) | грамм-нар | 50,0 | 60,0 | 70,0 | 60,0 |
| 22. | Каймак | грамм-нар | 10,0 | 10,0 | 11,0 | 10,3 |
| 23. | Сыр | грамм-нар | 10,0 | 12,0 | 12,0 | 11,3 |
| 24. | Атланмай | грамм-нар | 35,0 | 45,0 | 51,0 | 43,7 |
| 25. | Үсемлек мае | грамм-нар | 10,0 | 15,0 | 19,0 | 14,7 |
| 26. | Яшелчә табигый консервлар (яшел борчак, кукуруз, фасоль) | грамм-нар | 20,0 | 30,0 | 40,0 | 30,0 |
| 27. | Йомырка | данә | 1,0 | 1,0 | 1,0 | 1,0 |
| 28. | Икмәк пешерү өчен чүпрә | грамм-нар | 0,4 | 0,6 | 0,6 | 0,5 |
| 29. | Тоз | грамм-нар | 5,0 | 6,0 | 8,0 | 6,3 |
| 30. | Тәмләткечләр | грамм-нар | 1,0 | 2,0 | 2,0 | 1,7». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин